Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге
Рус Богдашкиносы авылы торак пунктында
гражданнар җыены КАРАРЫ

«6» ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, 2 гр инвалидларыннан тыш(I һәм II дәрәҗә хезмәт эшчәнлегенә сәләте чикләнгән очракта), балачактан инвалид булганнардан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Рус Богдашкино авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм вак таш һәм грунт катнашмасы салу (сатып алу, ташу, җәю);

Урам утларын ремонтлау һәм карап тоту (кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләре);

Зиратны төзекләндерү (хуҗалык блогын ремонтлау, килешү буенча башкарылган эшләр өчен түләү).

Җыенда рәислек итүче: А.Л. Михайлова

Богдашкино авыл җирлеге башлыгы: А.Л. Михайлова